БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12 август 2020 ел № 259

**Татарстан Республикасы
Балтач район Советы каршындагы
Яшьләр парламенты турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында Нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яшьләр парламентын төзү турында» 2015 елның 17 апрелендәге 271 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2020 елның 12 августыннан
259 номерлы карарына
1нче кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балтач район Советы каршындагы**
**Яшьләр парламенты турында**
**Нигезләмә**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советы каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба – Яшьләр парламенты) яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законлы җайга салу, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, яшьләр өчен закон чыгару эшчәнлеге күнекмәләрен үзләштерүдә шартлар тудыру һәм Россия яшьләр парламентаризмы хәрәкәтендә Татарстан Республикасы яшьләренең катнашуы өлкәсендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы (алга таба – Совет) эшчәнлегенә ярдәм итү максатларында төзелә.

2. Яшьләр парламенты Советның киңәшү һәм консультация бирү органы булып тора һәм үзенең эшчәнлеген әлеге Нигезләмә, Яшьләр парламенты регламенты нигезендә иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

3. Яшьләр парламенты вәкиллекле орган вәкаләтләре чорына төзелә.

**II. Яшьләр парламентының төп бурычлар**ы

4. Яшьләр парламентының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы муниципаль берәмлек территориясендә кулланыла торган норматив хокукый актлар (алга таба - норматив хокукый акт) эшләгәндә яшь гражданнарның инициативаларын белдерүгә ярдәм итү;

2) яшьләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендә норматив хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

3) муниципаль берәмлекнең яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый актлары проектларын карауга әзерләү буенча вәкиллекле орган эшчәнлегендә катнашу;

4) яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый актларына мониторинг үткәрү буенча вәкиллекле орган эшчәнлегендә катнашу;

5) Муниципаль берәмлек территориясендә яшьләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендәге законнарның үтәлешен иҗтимагый контрольдә тоту;

6) яшьләр арасында хокукый культураны һәм юридик грамоталылыкны арттыруга, актив гражданлык позициясен булдыруга юнәлдерелгән агарту һәм аңлату эшләре алып бару;

7) дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча җирле хакимият органнары эшчәнлеге турында яшь гражданнарның фикерләрен өйрәнү;

8) халыкара, гомумроссия, регионара, региональ һәм җирле яшьләр һәм балалар иҗтимагый оешмалары тарафыннан тәкъдим ителгән иҗтимагый әһәмиятле фикерләрне һәм инициативаларны хуплау һәм аларга ярдәм итү, тәҗрибә алмашу максатларында әлеге оешмалар белән даими хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

9) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты белән мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

10) Яшьләр парламенты төзү максатларына туры килә торган һәм законнарга каршы килми торган башка мәсьәләләрне хәл итү.

## III. Яшьләр парламенты составы һәм аны төзү тәртибе

5. Яшьләр парламенты әгъзалары итеп Россия Федерациясе территориясендә яшәүче, Яшьләр парламенты әгъзасы буларак вәкаләтләре расланган көнгә 18 яшьтән 35 яшькә кадәр (35 яшьне дә кертеп) булган Россия Федерациясе гражданнары сайланырга мөмкин.

6. Яшьләр парламенты конкурс нигезендә муниципаль берәмлек яшьләрен тәкъдим итүче гражданнардан - вәкиллекле органдагы депутатлар санына тигез санда кешедән төзелә;

7. Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән яшьләр вәкилләреннән торган Яшьләр парламентының персональ составы әлеге Нигезләмәгә кушымта итеп бирелгән Яшьләр парламентын формалаштыру буенча конкурс турында нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

8. Яшьләр парламенты составына тиешле муниципаль берәмлек яшьләрен тәкъдим итүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзалары керә. Яшьләр парламенты составына тиешле муниципаль берәмлек яшьләрен тәкъдим итүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзаларын кертү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

9. Яшьләр парламенты әгъзалары арасына Яшьләр парламенты составына кертелгән көнгә 35 яшькә кадәр булган вәкиллекле орган депутатлары кертелергә мөмкин. Вәкиллекле орган депутатларын Яшьләр парламенты составына кертү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

10. Яшьләр парламенты составына керү нияте турында гариза вәкиллекле орган депутаты тарафыннан Яшьләр парламенты Советына җибәрелә.

11. Яшьләр парламенты әгъзасы вәкиллекле органда фракциясе булган партия вәкиле (алга таба – партия вәкиле) булырга мөмкин. Партия вәкиле вәкиллекле органга сайлауларда тиешле партиядән кандидатларның исемлеге составына кергән, Яшьләр парламенты составына кертелгән көнгә 35 яшькә кадәр (35 яшьне дә кертеп) булган Россия Федерациясе гражданы булырга мөмкин. Партияләр вәкилләрен

Яшьләр парламенты составына кертү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

12. Яшьләр парламенты составына партия вәкилен кертү партия вәкиленең шәхси гаризасы һәм вәкиллекле органдагы тиешле фракциянең документлар белән рәсмиләштерелгән карары нигезендә Яшьләр парламенты Советы тарафыннан башкарыла. Яшьләр парламенты составына партиянең бер вәкиле кертелә

13. Узган чакырылыш Яшьләр парламенты Советы Яшьләр парламенты составының конкурс буенча сайланган вәкиллекле органдагы депутатлар санына тигез санда кешене, тиешле муниципаль берәмлек яшьләрен тәкъдим итүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзалары санын, составка конкурстан тыш кертелгән вәкиллекле орган депутатларын һәм партияләрдән вәкилләрне үз эченә ала торган йомгаклау санын билгели һәм Яшьләр парламенты әгъзаларының вәкаләтләрен раслый. Беренче чакырылыш Яшьләр парламенты составының йомгаклау санын билгеләү һәм аның әгъзалары вәкаләтләрен раслау муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы Советы тарафыннан, ә ул булмаганда - вәкиллекле орган тарафыннан башкарыла.

14. Әлеге Нигезләмәнең 6 пункты нигезендә үз кандидатурасын тәкъдим иткән Яшьләр парламенты әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда тәмамланган очракта тиешле исемлектәге иң күп санда тавыш җыйган чираттагы кандидат Яшьләр парламенты Советы карары нигезендә Яшьләр парламенты әгъзасы була. Әлеге карар Яшьләр парламенты Советы тарафыннан 10 көн эчендә кабул ителә.

15. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында күрсәтелгән исемлекләрдә иң күп санда тавыш җыйган башка кандидатлар булмаган очракта, Яшьләр парламенты әгъзалары әлеге Нигезләмә нигезендә конкурс уздыру юлы белән сайлап куела.

16. Конкурс нәтиҗәләре буенча Яшьләр парламенты әгъзаларының саны әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән санга туры килмәсә, Яшьләр парламенты составының санын тутыру өчен әгъзалар сайлау әлеге Нигезләмә нигезендә конкурс үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

17. Яшьләр парламенты регламентында каралган очракларда Яшьләр парламенты әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

## IV. Яшьләр парламенты эшен оештыру

18. Яшьләр парламентының беренче утырышы алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты Советы тарафыннан (беренче чакырылыш Яшьләр парламентының беренче утырышы – муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы Советы тарафыннан, ә ул булмаганда - вәкиллекле орган тарафыннан) чакырыла.

19. Яшьләр парламентының беренче утырышын алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты рәисе (беренче чакырылыш Яшьләр парламентының беренче утырышын – муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы рәисе, ә ул булмаганда - вәкиллекле орган вәкиле) ачып җибәрә.

20. Яшьләр парламенты әгъзалары беренче утырышта ачык тавыш бирү юлы белән Яшьләр парламенты әгъзалары арасыннан рәис, рәис урынбасарларын,

җаваплы секретарь сайлап куя, Яшьләр парламенты Советының санлы составын билгели һәм аның әгъзаларын сайлап куя, Яшьләр парламенты комиссияләрен төзи һәм аларның рәисләрен сайлап куя. Яшьләр парламенты рәисенә кандидатлар үзләренең эшчәнлек программалары белән чыгыш ясарга тиеш.

Яшьләр парламенты рәисе урынбасарларының саны Яшьләр парламенты рәисе тәкъдиме белән Яшьләр парламенты тарафыннан билгеләнә.

21. Яшьләр парламенты утырышы, әгәр анда Яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы була.

22. Яшьләр парламенты үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча эшче һәм эксперт төркемнәре төзергә, тәкъдимнәр эшләргә һәм кабул итәргә, аларны вәкиллекле орган һәм җирле үзидарә органнарына җибәрергә хокуклы.

23. Яшьләр парламенты карарын Яшьләр парламентының сайлап куелган әгъзалары санынннан күбрәге, шулай ук аның составына кертелгән тиешле муниципаль берәмлек яшьләрен тәгъдим итүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзалары, вәкиллекле орган депутатлары, партияләр әгъзалары хуплап тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала.

24. Яшьләр парламенты советын Яшьләр парламенты рәисе җитәкли, аның вәкаләтләре Яшьләр парламенты регламенты белән билгеләнә.

25. Яшьләр парламенты Советы:

1) Яшьләр парламенты һәм аның комиссияләре эшен оештыра һәм координацияли;

2) Яшьләр парламенты регламентын эшли һәм аны Яшьләр парламенты раславына тәкъдим итә;

3) чираттагы елга Яшьләр парламентының эш планнарын әзерли һәм аларны Яшьләр парламентына раслауга тәкъдим итә;

4) Яшьләр парламенты регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

26. Яшьләр парламенты комиссияләре үз функцияләре нигезендә эшләрен оештыра һәм яшьләр парламенты утырышларында карау өчен тәкъдимнәр һәм карарлар проектларын әзерли.

27. Яшьләр парламенты эшендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Дәүләт Советы депутатлары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле орган депутатлары, шулай ук чакыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә җитәкчеләре, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары вәкилләре, Татарстан Республикасы территориясендә эш итүче сәяси партияләр һәм иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар катнаша ала.

Татарстан Республикасы
Балтач район Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында нигезләмәгә кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балтач район Советы каршындагы**
**Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс турында**
**Нигезләмә**

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балтач район Советы каршындагы Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс үткәрүнең гомуми принципларын һәм тәртибен билгели (алга таба – конкурс).

2. Конкурс Татарстан Республикасы Балтач район Советы каршындагы Яшьләр парламентының Яшьләр парламенты турында нигезләмәнең 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы каршындагы Яшьләр парламентындагы (алга таба - вәкиллекле органдагы) депутатлары санына тигез санда кешедән торган составын формалаштыру максатында үткәрелә.

## II. КОНКУРСНЫ ОЕШТЫРУЧЫ

3. Конкурсны оештыруны һәм үткәрүне оештыру комитеты (алга таба - Комитет) гамәлгә ашыра.

4. Комитет составы паритет нигезендә вәкиллекле орган, алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты (беренче чакырылыш Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс үткәрелгәндә – муниципаль берәмлекнең вәкиллекле орган каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы вәкилләре), яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең башкарма хакимияте органы вәкилләреннән төзелә.

5. Комитет составы, шул исәптән аның Рәисе, алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты карары (беренче чакырылыш Яшьләр парламентын формалаштыру буенча конкурс үткәрә торган Комитетка карата – вәкиллекле орган каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы карары, ә ул булмаган очракта - вәкиллекле орган карары белән) белән расланa. Комитет составы 3 кешедән ким була алмый.

6. Комитет:

1) конкурста катнашу өчен Интернет челтәрендә конкурсның рәсми мәгълүмат ресурсы булган сайтта (http://molparlament.tatar) (алга таба – мәгълүмат сайты) гаризалар кабул итә;

2) конкурста катнашучылар белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

3) конкурска йомгак ясый;

4) әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

7. Комитет утырышы, әгәр анда Комитетның расланган әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

8. Комитет карары утырышта катнашучылар санныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта Комитет рәисенең тавышы хәлиткеч

була.

9. Комитет вәкаләтләре Яшьләр парламенты составының йомгаклау санын раслаганнан соң туктатыла.

## III. КОНКУРСНЫ ҮТКӘРҮ ШАРТЛАРЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ

10. Конкурсны игълан итү, шул исәптән аны үткәрү вакыты турында карар алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты тарафыннан кабул ителә. Беренче чакырылыш Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс игълан итү турында карар вәкиллекле орган каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы тарафыннан, ә ул булмаган очракта - вәкиллекле орган тарафыннан кабул ителә.

11. Конкурсны игълан итү турында карар, конкурсны үткәрү шартлары һәм сроклары турында мәгълүмат конкурсны игълан итү турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә Комитет тарафыннан мәгълүмат сайтына урнаштырыла, шулай ук вәкиллекле органның Интернет челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыру өчен җибәрелә.

12. Яшьләр парламенты әгъзаларына кандидатлар Яшьләр парламенты турында нигезләмәнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

Конкурста Яшьләр парламенты әгъзасына кандидатлар сыйфатында юкка чыгарылмаган (кире алынмаган) суд хөкеме булган, шулай ук Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.3 һәм 20.29 статьяларында каралган административ хокук бозуларны кылган өчен административ җаваплылыкка тартылган (җәлеп ителгән) затлар катнаша алмый.

13. Конкурс этаплап үткәрелә.

14. Конкурсның беренче этабы Конкурста катнашырга теләк белдергән гражданнар тарафыннан гаризалар кабул итүне үз эченә ала.

15. Гаризалар электрон рәвештә мәгълүмат сайтына тапшырыла.

16. Гариза составына түбәндәгеләр керә:

1) алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты карары белән (беренче чакырылыш Яшьләр парламенты составын формалаштырганда - вәкиллекле орган каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы карары белән, ә ул булмаганда - вәкиллекле орган карары белән) билгеләнгән рәвештә тапшырылган шәхси гариза;

2) кандидатның алдагы состав Яшьләр парламенты карары белән (беренче чакырылыш Яшьләр парламенты составын формалаштырганда - вәкиллекле орган каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы карары белән, ә ул булмаганда - вәкиллекле орган карары белән) билгеләнгән рәвештә тапшырылган анкетасы. Анкетада конкурста катнашу өчен үз кандидатурасын тәкъдим иткән гражданның әлеге Нигезләмәнең 12 пунктындагы таләпләргә туры килүен билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар мәҗбүри рәвештә күрсәтелергә тиеш;

3) гражданның шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы.

18. Тапшырылган (җибәрелгән) гаризалар Комитет тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Комитет гаризаны кабул итү һәм конкурсның киләсе этабында катнашырга рөхсәт бирү турында карар кабул итә. Киләсе этапта катнашуга рөхсәт бирелгәннәргә Яшьләр парламенты әгъзасына кандидат (алга таба – кандидат) статусы бирелә.

19. Конкурсның икенче этабы яшьләрне Яшьләр парламенты составын формалаштыру буенча конкурс нигезендә тавыш бирүгә җәлеп итү буенча кандидатлар катнашында чаралар үткәрүне үз эченә ала.

20. Комитет кандидатлар катнашында үткәрелә торган чаралар исемлеген булдыра. Һәр кандидат үзе тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә торган кимендә бер чарада катнашырга тиеш. Кандидат чарада катнашмаган очракта, Комитет аны конкурста катнашудан төшереп калдыра.

Кандидат үзен хуплату өчен законга каршы килми торган чараларны мөстәкыйль рәвештә үткәрергә хокуклы.

21. Өченче этап кандидатлар өчен тавыш бирүне үткәрүдән гыйбарәт.

22. Кандидатлар өчен тавыш бирү Интернет челтәре сайтында үткәрелә https://open.tatarstan.ru/polls (алга таба – тавыш бирү сайты).

23. Тавыш бирүдә Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче 14 яшьтән 35 яшькә кадәр булган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – тавыш бирүдә катнашучы) катнаша ала.

24. Тавыш бирүдә катнашучы чикләнмәгән сандагы кандидатлар өчен тавыш бирергә хокуклы. Шул ук вакытта муниципаль берәмлектән кандидат өчен бары тик Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлеге территориясендә яши торган тавыш бирүдә катнашучы гына тавыш бирергә хокуклы.

25. Тавыш бирүдә катнашучы кандидатлар өчен бер генә тапкыр тавыш бирергә хокуклы.

26. Дүртенче этап конкурсның тавыш бирү нәтиҗәләрен ясауны һәм бастырып чыгаруны үз эченә ала.

27. Конкурста Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлектә иң күп тавыш җыйган кандидатлар җиңүче дип таныла.

28. Тавыш бирү нәтиҗәләре http://molparlament.tatar мәгълүмат сайтында урнаштырыла.

29. Конкурсны үткәрү срогы, шул исәптән конкурсның һәр этабы срогы, конкурсны үткәрү турындагы карарда билгеләнә.